КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 22 декабрь г.Казань № 1266

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карары белән расланган Сөт бирә торган терлекчелектә продуктивлыкны арттыруга юнәлдерелгән чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 5 август, 680 нче; 2021 ел, 31 август, 788 нче; 2021 ел, 7 сентябрь, 835 нче; 2021 ел, 25 ноябрь, 1127 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Сөт бирә торган терлекчелектә продуктивлыкны арттыруга юнәлдерелгән чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Министрлык сайлап алу нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган көннән 15 эш көне эчендә субсидия алучылар белән килешүләр төзи:

бу Тәртипнең 17 пункты нигезендә исәпләп чыгарыла торган субсидияне алу өчен – Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә;

бу Тәртипнең 18 пункты нигезендә исәпләп чыгарыла торган субсидияне алу өчен – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә.

Бу Тәртипнең 17 пункты нигезендә исәпләп чыгарыла торган субсидияне алу өчен килешү иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең «Электрон бюджет» дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында электрон документ формасында төзелә һәм һәр як исеменнән эш итәргә хокуклы затлар тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, аны күчерү тәртибе;

субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткече;

Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр йомгаклары буенча аны бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен бозу фактлары билгеләнгән очракта, Татарстан Республикасы бюджетына субсидияне кире кайтару тәртибе;

субсидия алучы тарафыннан Министрлык тарафыннан билгеләнгән өстәмә хисапларны бирү формасы һәм сроклары;

бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән, элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары Министрлыкка киметелгән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча килешүгә ирешеп булмаганда килешүне өзү турында, субсидияне килешүдә билгеләнгән күләмдә бирү мөмкин булмавына китерә торган шарт.

Кирәк булганда Министрлык субсидия алучылар белән килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи:

бу Тәртипнең 17 пункты нигезендә исәпләп чыгарыла торган субсидияне алу өчен – Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә;

бу Тәртипнең 18 пункты нигезендә исәпләп чыгарыла торган субсидияне алу өчен – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин